Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешү

Олы Кайбыч ав.    «27» декабрь, 2024ел

Бергә «яклар» дип аталучы, алга таба «җирлек Башкарма комитеты» дип аталачак Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитеты исеменнән, Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге нигезләмәсе нигезендә эш итүче Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Матвеева Светлана Петр кызы бер яктан, һәм алга таба «район Башкарма комитеты» дип аталачак, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты исеменнән, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы нигезләмәсе нигезендә эш итүче Башкарма комитет җитәкчесе (муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе ФИА), икенче яктан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә таянып, түбәндәге килешүне төзеделәр:

## 1. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешү җирлек Башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны район Башкарма комитетына тапшыруны беркетә.

1.2. Җирлек башкарма комитеты түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны район Башкарма комитетына тапшыра:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

1.3. Яклар әлеге Килешүне гамәлгә ашыру кысаларында мәгълүмат алмашырга йөкләмә ала.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1.Район Башкарма комитеты җирлек Башкарма комитеты тапшырган вәкаләтләрне шушы Килешүнең 1 бүлеге нигезендә гамәлгә ашыра.

2.2. Район Башкарма комитеты Нигезләмә буенча әлеге килешү нигезендә тапшырылган вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашырачак вазыйфаи затны яисә

структур бүлекчәне билгели.

2.3. Район Башкарма комитеты җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген күрсәтү кысаларында эшләр башкару өчен физик яки юридик затлар белән контракт (килешү) төзи.

2.4. Әлеге килешү буенча тапшырылган вәкаләтләр кысаларында эшчәнлекне гамәлгә ашыру өлешендә район Башкарма комитеты җирлек Башкарма комитетына хисап тота.

## 3. Бюджетара трансфертларның еллык күләмен билгеләү тәртибе

3.1. Әлеге Килешү предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен башкаруны гамәлгә ашыру ел саен җирлек бюджетыннан муниципаль район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3.2. Яклар ел саен бюджет турында ел саен раслана торган карарлар нигезендә (әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булган кушымталар нигезендә) тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләмен билгели.

3.3. Шушы килешүнең 1.2 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирлек бюджетыннан муниципаль район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертларны формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4. Килешүнең гамәлдә булу вакыты, нигезләре һәм гамәлдән чыгару тәртибе

4.1. Әлеге Килешү рәсми рәвештә халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4.2 Әлеге Килешү 2026 елның «31» декабрь аена кадәр гамәлдә була.

4.3.Әлеге килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

яклар килешүе буенча;

якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән йә килешүнең алга таба гамәлдә булмавына китерә торган гамәлдәге законнар үзгәргән очракта берьяклы тәртиптә.

Әлеге килешүне өзү турында хәбәрнамә аның гамәлдә булу вакыты тәмамлану датасына кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча икенче якка язма рәвештә җибәрелә.

4.4. Әлеге килешү буенча тапшырыла торган кайбер вәкаләтләрне туктату башка вәкаләтләрне туктатуга китерми.

4.5. Әгәр яклар шушы Килешүнең 4.2 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң утыз көн эчендә килешүне өзәргә ниятләүләрен белдермәсәләр, ул киләсе календарь ел тәмамланганчы озайтылган дип санала.

## 5. Якларның җаваплылыгы

5.1.Яклар гамәлдәге законнар нигезендә әлеге Килешүдә каралган бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

5.2.Район Башкарма комитетының үзенә тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә башкармавы әлеге килешүне берьяклы өзү өчен нигез булып тора. Килешүне өзү,

документаль рәвештә расланган факттагы чыгымнарны исәпкә алмаганда, санап үтелгән бюджетара трансфертларны өзү турында Килешүгә кул куелганнан яисә аны өзү турында язма хәбәрнамә алынганнан соң 30 көн эчендә кире кайтаруга, шулай ук хисап елында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен жирлек бюджетыннан бүлеп бирелә торган бюджетара трансфертлар суммасыннан 0,01% күләмендә неустойка түләүгә китерә.

5.3. Район башкарма комитеты үзенә тапшырылган вәкаләтләрне финанс средстволары белән тәэмин ителгән дәрәҗәдә башкару өчен җаваплы.

5.4.Җирлек башкарма комитеты аңа тапшырылган вәкаләтләрне башкаруны финанслау буенча әлеге килешүдән килеп чыга торган йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, район Башкарма комитеты әлеге Килешүне өзүне, шулай ук китерелгән зыянны каплауны таләп итәргә хокуклы.

6. Башка мәсьәләләр

6.1.Якларның үзара ризалыгы буенча яисә гамәлдәге законнар таләпләре нигезендә әлеге килешүгә язма рәвештә әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булып торучы үзгәрешләр һәм (яисә) өстәмәләр кертелергә мөмкин.

6.2. Әлеге Килешүне үтәгәндә яклар тарафыннан җайга салынмаган бәхәсләр һәм каршылыклар гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә каралырга тиеш.

6.3 Әлеге Килешү бертигез юридик көчкә ия 2 (ике) нөсхәдә, һәр як өчен берәр нөсхәдә төзелде.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитеты,<br>адресы: 422326, ТР, Кайбыч районы, Хуҗа Хәсән ав., Ольга Данилова ур., 16 й.,<br>җирлекнең Башкарма комитет җитәкчесе С.П.Матвеева<br>________________ (имза) | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты,<br>адрес: 422330, ТР, Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7й.<br>район Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Н.Макаров<br>________________ (имза) |

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЙБИЦКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОГРН 1061673006350 ИНН 1621003052 ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ Хозесановского сельского поселения

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОГРН 1061673000782 ИНН 1621002965